**З.Н.Кириллова**
*Казанский (Приволжский) федеральный университет*

# Төрки тел белеменең күренекле вәкиле Флера Сафиуллина

*тюркология, татар теле, Ф.С.Сафиуллина, синтаксис, тел укыту*

Флера Садри кызы Сафиуллина – тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Халыкара төрки академия академигы, татар тел белеме һәм тюркология өлкәсендәге фәнни хезмәтләре белән Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, дөньяның күп илләрендә танылган галимә.

Флера Сафиуллина Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. 1960 елда аны кызыл диплом белән тәмамлагач, университетның яңа оешкан татар теле кафедрасында башта лаборант булып эшли, бер елдан исә ассистент вазифасын үти башлый. 1962-1965 елларда күренекле галим М.З. Зәкиев җитәкчелегендә аспирантура үтеп, 1966 елда “Татар телендә сүз тәртибе” дигән темага кандидатлык диссертациясен бик уңышлы итеп яклап чыга һәм филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ия була. Бу диссертация тагын да эшкәртелеп, соңрак аерым китап булып басылып чыга [Сафиуллина 1974]. Хезмәттә татар телендәге сүз тәртибе мәсьәләләре тикшерелә: сүз тәртибен билгеләүче факторлар, җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше, грамматик кисәкләрнең урнашу тәртибе, инверсия, сөйләм телендә сүз тәртибе, сүз тәртибенә нигезләнгән стилистик чаралар җентекләп анализлана.

Ф.С.Сафиуллина университетның татар теле кафедрасында 1972 елдан доцент дәрәҗәсендә эшли башлый. Ул гаять күп төрле дәресләр укыта: “Тел белеменә кереш”, “Татар әдәби теленең синтаксисы”, “Татар теленең тарихи синтаксисы”, “Татар сөйләм теле синтаксисы”, “Татар теленең лексикологиясе”, “Тәрҗемә теориясе һәм практикасы”, “Чит аудиториядә татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре”, “Текст стилистикасы” һ.б. Әлеге дәрес материаллары нигезендә монографияләр, дәреслекләр, уку-укыту кулланмалары һәм программалар бастырып чыгара.

Җәмгыятьтә 1980 нче еллар уртасында башланып киткән кискен үзгәрешләр 1989 елда Казан дәүләт университетында татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты ачылуга мөмкинлек бирә. Татар теле яңадан дәүләт теле буларак яши башлагач, 1992 елда «Чит телле аудиториядә татар теле» кафедрасы төзелә һәм Ф.С.Сафиуллина шул кафедраның мөдире итеп билгеләнә. Ул тиз арада кафедраны аякка бастыра, укытучылар туплый, аспирантлар әзерли, диплом эшләре

яздыра, күп санлы кулланмалар һәм дәреслекләр яза. Кафедра белән 70 яшенә – 2008 елга кадәр җитәкчелек итә.

1990 нчы елларда Флера Садриевна “Идел”, “Татарстан” журналларында, “Известия Татарстана” газетасында татар теленә өйрәтү дәресләре бастырып килә һәм татар теленең яңа үзөйрәткечләрен, сөйләүлекләрен, күп сүзлекләр төзеп бастыра. Галимә җитәкчелегендә чит ил һәм Россия университетлары белән фәнни-тикшеренү элемтәләре булдырыла. Ул Берлинның Азат университетындагы Тюркология институты белән хезмәттәшлек итә, алман студентларына татар теленнән дәресләр бирә, Хельсинкида яшәүче фин татарларына лекцияләр укый. Моннан тыш, Казан университетына тел өйрәнү максаты белән килгән бик күп чит ил – Алмания, Швейцария, Англия, Америка, Корея, Кытай, Монголия, Япония һ.б. ил вәкилләренә, шулай ук университетның башка бүлекләрендә укучы студентларга татар теле өйрәтә. Шул рәвешчә, галимә татар теленең дәүләт теле буларак яшәешенә, татар телен чит тел сыйфатында өйрәтүгә үзеннән зур өлеш кертә.

Ф.С.Сафиуллина 2000 елда “Татар әдәби теле синтаксисының үсеше (XX гасыр)” дигән темага докторлык диссертациясе яклый. Диссертация Мәскәү, Казан, Уфа, Чабаксар тюрколог-галимнәре тарафыннан бик югары бәяләнә. Әлеге диссертация буенча монографияләр чыга, лекцияләр укыла, махсус курс программалары төзелә.

Профессор Ф.С.Сафиуллина – биш йөзгә якын фәнни хезмәт авторы. Алар арасында фәнни монографияләр һәм мәкаләләрне, татар теленнән төрле уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку-укыту әсбапларын, фәнни-методик хезмәтләрне һәм күп санлы конференцияләрдә ясаган чыгышларны аерып күрсәтергә мөмкин. Хезмәтләре арасында татар теленең синтаксисы, лексикологиясе, стилистикасы, рус һәм татар телләренең чагыштырма грамматикасы, татар теленә өйрәтү методикасы, югары уку йортлары, мәктәпләр, колледжлар, гимназияләр өчен дәреслекләр һәм программалар зур урын алып тора.

Шулай ук Флера Садриевна – күп төрле сүзлекләр авторы да: ул, татар лексикографиясендә беренчеләрдән булып, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләре, татарча-русча, русча-татарча кесә сүзлекләре, татарча-русча фразеологик сүзлек, татарча-русча лингвистик терминнар сүзлеге, балалар өчен рәсемле сүзлекләр, инглизчә-татарча-русча уку-укыту сүзлеге һ.б. әзерләп бастыра.

Гомумән, татар тел белеменең кайсы гына тармагын алып карасаң да, аның нигезендә Флера Сафиуллинаның фәнни-теоретик хезмәтләре ята. Шулай да ул – иң беренче чиратта, синтаксист галим. Татар әдәби теленең синтаксик төзелешен өйрәнеп язылган күп санлы монографияләрендә һәм фәнни мәкаләләрендә татар синтаксисы фәненең актуаль мәсьәләләре күтәрелә, гади һәм кушма җөмлә төзелешендәге үзгәрешләр, татар синтаксик системасының үсеш тенденцияләре билгеләнә.

Ф.С.Сафиуллина татар синтаксисының яңа юнәлешенә – сөйләм теле синтаксисына нигез сала һәм аны аерым фән дәрәҗәсенә күтәрә.

Татар сөйләм теленең синтаксик үзенчәлекләрен өйрәнү нәтиҗәләре аның 1978 елда басылган күләмле монографиясендә яктыртыла [Сафиуллина 1978]. Хезмәттә диалогик сөйләмнең төзелеш үзенчәлекләре һәм татар сөйләмендә очрый торган типик төзелмәләр, табигый һәм алдан әзерләнмәгән җанлы сөйләмнең үзенчәлеген чагылдырган кабатлаулар, раслау һәм инкяр җөмләләр, эллиптик төзелмәләр һ.б. синтаксик күренешләр җентекләп тикшерелә, шулар нигезендә, галимә татар синтаксисының яңа юнәлешләре булган диалекталь һәм экспрессив синтаксисны өйрәнүне башлап җибәрә.

Флера Сафиуллинаның 1990 елда дөнья күргән һәм татар теле синтаксисының совет чорындагы үсешен тикшерүгә багышланган монографиясе татар теленең синтаксик төзелешен, аның үсеш закончалыкларын бөтен нечкәлекләре белән аңлатып язылган бик әһәмиятле фәнни хезмәт булып тора [Сафиуллина 1990]. Әлеге хезмәт фикер тирәнлеге, искиткеч зур фактик материалга нигезләнеп язылуы белән татар тел белемендә генә түгел, гомумән, тюркологиядә югары бәяләнә.

1993 елда Ф.С.Сафиуллина тарафыннан сөйләмнең иң зур берәмлеге булган текстны өйрәнүгә багышланган “Текст төзелеше” дип аталган монография басылып чыга. Бу китапта сөйләмнең төп үзенчәлекләрен чагылдырган текст һәм аның төзелеше турында сүз бара. Автор үзе бу хезмәтен үткән елларда синтаксис буенча чыккан хезмәтләренең табигый үстерелеше дип саный [Сафиуллина 1993: 3]. Татар язучылары Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ә. Еники һәм Г. Исхакыйның поэтик синтаксисын тикшереп, галимә татар сөйләменең синтаксик байлыгын һәм аһәңен күрсәтүгә ирешә.

Болардан тыш, Флера Сафиуллинаның күп еллык гыйльми тикшеренүләре һәм югары уку йортларында укыту тәҗрибәсе нигезендә эшләнгән югары сыйфатлы дәреслекләре, мәктәп һәм вуз программалары ярты гасыр дәвамында татар синтаксисы фәненә һәм синтаксисны укыту методикасына хезмәт итеп килә. Югары уку йортларында, педагогия колледжларында татар теле синтаксисы Ф.С.Сафиуллинаның фәнни хезмәтләренә, дәреслекләренә нигезләнеп укытыла. Галимәнең синтаксис буенча язылган методик кулланмалары, ярдәмлекләре бүгенге көндә дә студентлар, татар теле укытучылары өчен төп ярдәмлек хезмәтен үти.

Ф.С.Сафиуллина татар һәм рус телләренең чагыштырма синтаксисын өйрәнүгә дә үзеннән зур өлеш кертә. Бу юнәлештә аның төрле елларда М.З.Зәкиев, Л.К.Бәйрәмова, С.М.Ибраһимов һәм К.З.Зиннәтуллина белән берлектә язган дәреслек-кулланмалары [Сафиуллина 2007] тел белгечләре, тәрҗемәчеләр өчен дә әһәмиятле хезмәт булып тора.

Флера Садри кызы Сафиуллина – Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, татар мәгарифен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Каюм Насыйри исемендәге премия иясе, Халыкара төрки академия әгъзасы. 2000 елда ул “Хезмәтем – бәхетем” номинациясендә “Ел ха-

тын-кызы” исеменә лаек була һәм “Сөембикә” журналының “Сөембикә беләзеге” белән бүләкләнә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру комитеты әгъзасы, “Сөембикә”, “Ялкын”, “Мәгариф” журналларының редколлегия әгъзасы була.

Флера Садриевна яшь буынның, аспирантларының гаҗәеп остазы да була. Аның җитәкчелегендә татар тел белеменең актуаль мәсьәләләре буенча дистәдән артык кандидатлык диссертациясе яклана. Шул рәвешчә, Ф.С. Сафиуллина – үзенең көчле фәнни мәктәбен булдырган галимә.

Казан дәүләт университетында Флера Садриевнадан дәресләр алган студентлар аны бик яхшы укытучы, фәнни җитәкче, оештыручы буларак беләләр. Ул студентларны үзенә гашыйк итә белә торган кеше иде. Тирән белеме, киң күзаллавы, заманча фикерләре, матур тавышы һәр студентны фән дигән серле дөньяга өнди, ул оештырган “Тел бәйгеләре”, татар теле олимпиадалары, танылган галимнәр белән очрашулар, төрле кичәләр һәр студентның күңелендә озак еллар буе саклана.

Флера апа шәхси сыйфатлары ягыннан да күркәм кеше иде: ул бик кешелекле, намуслы, тырыш, ачык күңелле, юмарт һәм кунакчыл булуы белән аерылып торды. Ягымлы тавышы белән бик матур итеп сөйли, моңлы итеп җырлый иде. Юкка гына аны татар язучысы Рафаил Сибат “чәчәк телле галимә” [Фәнгә 2008: 77; Казан 2013: 5] дип атамагандыр. Һәркемгә гаять дәрәҗәдә игътибарлы булып, кулыннан килгәнчә ярдәм итеп яшәде. Бигрәк тә үзенең кафедрасы укытучыларын һәм аспирантларын балалары урынына күреп, эш буенча да, гаиләкөнкүрешләрен җайга салырга да ярдәм итеп килде. Өенә яки кафедрасына кергән һәркемне тәмле сый-нигъмәтләре белән кунак итә, китапларын ихлас күңелдән бүләккә өләшеп бетерә, олысын-кечесен тиң күреп сөйләшә иде. Шундый сыйфатлары белән ул һәркемнең күңелендә бары җылы хисләр генә калдырды.

Гомумиләштереп әйткәндә, Флера Садри кызы Сафиуллинаның эшчәнлеге күп юнәлешле һәм бик тирән эчтәлекле иде. Тел гыйлеменә кереш һәм татар әдәби теленең төрле өлкәләре буенча язылган, татар һәм төрки тел белеменең үсешенә зур өлеш керткән күп санлы фәнни хезмәтләре, татар телен фән теле буларак та, чит тел сыйфатында да укыту эшчәнлеге, актив җәмәгать эше белән дә, кешелек сыйфатлары ягыннан да ул кабатланмас шәхес булды.

**Әдәбият**


Казан университетында – ярты гасыр. – Казан: Ихлас, 2013. – 220 б.

Сафиуллина Ф.С. Татар телендә сүз тәртибе / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Тат. китап нәшр., 1974. – 150 б.

Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи / Ф.С.Сафиуллина. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. – 150 с.

Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период (простое предложение) / Ф.С.Сафиуллина. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. – 230 с.

Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 263 б.

Сафиуллина Ф.С. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков / Ф.С.Сафиуллина. – Казань: Тат. кн. изд-во, 2007. – 230 с.

Фәнгә багышланган гомер. – Казан: КДУ нәшр., 2008. – 213 б.